**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 август № 576

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ буларак теркәлгән гаиләгә һәр бала туганда, уллыкка (кызлыкка) алынганда түләүләр гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау хакында» 2012 ел, 31 август, 748 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 май, 321 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәменә мохтаҗ буларак теркәлгән гаиләгә һәр бала туганда, уллыкка (кызлыкка) алынганда түләүләр гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктның икенче абзацында «социаль ипотека шартнамәсе буенча» сүзләреннән соң «әлеге торак урында баланың уртак өлешле милек хокукы барлыкка килгәннән соң» сүзләрен өстәргә;

гариза формасында (Кагыйдәләргә 1 нче кушымта) «сорыйм» сүзләренә кадәр «составка баланы кертеп, исәп-хисап эшенә һәм социаль ипотека шартнамәсенә үзгәрешләр кертүегезне һәм...» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 8 август, 366 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнар түләүләрен кичектереп тору шартларын һәм вакытларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Гаилә әлеге хокукын гамәлгә ашырганда баланың сатып алына торган торак урынга, аның тулы кыйммәтен түләгәннән соң, уртак өлешле милек хокукы барлыкка килә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков